**Фазылова, Руфия.** Бакый Урманче музее. – Текст: турыдан-туры, электрон / Р. Фазылова // Татарстан. – 2020. – №1 (337). – С. 54-57. – URL: http://protatarstan.ru/bakyi-urmanche-muzee/




Бакый Идрис улы Урманченың татар профессиональ сынлы сәнгатенә нигез салган олуг рәссам. Татарстан сынлы сәнгатен үстерү белән бергә, Казахстан, Үзбәкстан сәнгатьләре үсешенә дә үзеннән бәяләп бетергесез зур өлеш кертә. Җитмеш елдан артык сәнгатькә хезмәт итү дәверендә Бакый Урманче дүрт йөзгә якын нәкыш, йөз илледән артык скульптура һәм кәгазь битләрендә меңнәрчә график әсәрләр иҗат итә.

«Бакый Урманче исемен ишетмәгән татар кешесе юктыр дип уйлыйм. Аны татар сынлы сәнгатенә үзеннән искиткеч олы өлеш керткән атаклы сынчы, талантлы, күпкырлы иҗади мирас калдырган рәссам буларак беләбез. Рәсем сәнгате белән сынлы сәнгать – аның ике канаты. Шунысы кызык: сынчылар Бакый аганы: «Ул безгә юл күрсәтте», – ди, рәссамнар исә: «Юк, ул – безнеке», – ди. Боларга өстәп, Урманче турында тагын нәкыш, графика остасы дип тә әйтергә кирәк. Хәер, бик күп нәрсә белән кызыксына, мавыга, үзен сынап карый ул тормышта…» дип яза Руфия Фазылова үзенең мәкаләсендә. Бу мәкаләдә сүз бөек шәхеснең биографиясе һәм иҗаты, шулай ук 1999 елда ачылган Бакый Урманче музее турында да.



Автор сүзләре буенча: «Анда килеп кергәч тә, үзеңә төбәлгән карашларны тоясың. Әле кемнәр генә карый бит: татарның берсеннән-берсе затлы, даһи уллары – Тукай, Әмирхан, Мәрҗани, Дәрдемәнд, Җиһанов… Ул ясаган сыннар шул дәрәҗәдә җанлы булып күренәләр ки, килеп сүз кушардай буласың… Бакый Урманче музеендагы сыннар безне әнә шулай чынбарлыктан ерак үткәннәргә алып китте…» Тулырак бу музей турында «Татарстан» журналында укый аласыз.